ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.11.2018 с. Верхний Услон 1314

2018 елга салым салынырга тиешле
гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының
иң чик күләмнәрен раслау турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм күрсәтелгән законга Кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, «2018 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2018 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2017 елның 20 декабрендәге 1691/пр номерлы боерыгы, шулай ук Торак кодексының 49, 51 маддәләренә таянып, Югары Ослан районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен минималь чик күләмен раслау турында:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен –1 233 474 сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен –1 569 876 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаиләләр – 2 018 412 сум;

1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен – 2 691 216 сум;

1.1.5. биш кешелек гаилә өчен –3 364 020 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 4 036 824 сум;

1.1.7.җиде кешелек гаилә өчен – 4 709 628 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык минималь керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен –13467 сум;

1.2.2. ике кешелек гаилә өчен –8 567 сум;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешелек гаилә өчен – 7 344 сум;

2. Район Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, элемтә һәм энергетика бүлегенә, районның авыл җирлекләре Башкарма комитетларына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда һәм социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бүлеп биргәндә файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Л.С. Хакимзянов**

Әзерләде һәм бастырды
:Бурдина Т.Н.
5 нөсхәдә

**2018 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү**

# МЕТОДИКАСЫ

1. **Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече**

**СЖ = НП*РС*РЦ, монда**

СЖ - исәп-хисап күрсәткече базар бәясе яки милек бәясе чиге;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - РФ төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгы тарафыннан расланган 1 кв. м мәйданның уртача исәп-хисап бәясе (икенче яртыеллыкка һәм 2018 елның өченче кварталына – 41879,0 сум)

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 37 378*33=1 233 474

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 37 378*42=1 569 876

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 37 378*18*3=2 018 412

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 37 378*18*4=2 691 216

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 37 378*18*5=3 364 020

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ= 37 378*18*6=4 036 824

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 37 378*18*7=4 709 628

**2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме**

**ПД =0,7*СЖ*ПС/ {1-[(1+ПС) - КП]} / (0,3*РС), монда**

СЖ – социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

ПС – бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (14/12);

КП – кредит буенча бөтен вакыты өчен кредит түләүләрнең гомуми саны (Ай саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7- кредит суммасы һәм фатир бәясе   чагыштырмасы;

0,3-  кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык кереме белән чагыштырмасы;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = (0,7*1 233 474*1,16) / {1- [(1+1,16) -250]} / (0,3*1)= 13467

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = (0,7*1 569 876*1,16) / {1- [(1+1,16)-250]} / (0,3*2)= 8 567

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД = (0,7*2 018 412 *1,16) / {1- [(1+1,16)-250]} / (0,3*3)= 7 344